**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 4 мартындагы 518 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 28 октябрендәге 4553 номерлы «2025 елга Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

2025 елга Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә азык-төлек продуктлары чыгымнарына 2025 елга өстәмә индексация булуга бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 28 октябрендәге 4553 номерлы «2025 елга Казан шәһәрендә мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»гы карарының 1 номерлы кушымтасына, 4 пунктны әлеге карарның кушымтасындагы редакциядә биреп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2025 елның 1 апреленнән барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның  4 мартындагы
518 номерлы карарына
кушымта

4. Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативы

| **Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны** | **Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативы, көнгә/тәрбияләнүче** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | **гомуми үсеш төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәге)** | | **шифаханә төркемнәре, шул исәптән еш авыручы балалар төркемнәре** | | | |
| | **2 айдан 3 яшькә кадәр** | **3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганчыга кадәр** | **2 айдан 3 яшькә кадәр** | **3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы** | **«целиакия» авыруы булган балалар өчен 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганчы** | **«фенилкетонурия» авыруы булган балалар өчен 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганчы** |
| 3-4 | 33,88 | 42,65 | | | 0 | 0 |
| 5-6 | 81,28 | 102,39 | | | 0 | 0 |
| 7-12 | 135,49 | 170,64 | 175,78 | 234,39 | 304,90 | 402,72 |
| 24 | 169,34 | 210,66 | 219,73 | 289,36 | 0 | 0 |